МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__14.04.2023__ Казан ш. №___68-ОД___

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 308-ОД номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 308-ОД номерлы боерыгына үзгәреш кертеп, 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Әлеге боерык белән расланган Исемлекне Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә ул расланган көннән алып өч көн эчендә тапшырырга, ә аннан соң, аңа үзгәрешләр

кертелгәндә, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә төгәлләнгән исемлекләрне тапшырырга».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко